Әлмәт муниципаль районы Башлыгы
карары

17 март 2020 ел № 17

Гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әлмәт муниципаль районында гавами тыңлаулар уздыру турындагы нигезләмә хакында» 2008 елның 4 апрелендәге 234 номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карарына таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Яңа Никольский авыл җирлеге, Сосновка б., Садовая ур., 3 з/у адресы буенча урнашкан16:07:230001:1432 кадастр номерлы җир кишәрлегенә карата кызыл сызыкларны үзгәртү өлешендә территорияне ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты – 2020 елның 27 мартында 11:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү вакыты - әлеге карар басылып чыккан көннән алып кимендә бер айдан да ким һәм өч айдан да артык булмаган вакытка.

2.3. Үткәрү урыны-Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Яңа Никольский авыл җирлеге, Новоникольск авылы, Центральная ур., 100 йорт.

2.4. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре шәһәр җирлеге, Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай проспекты, 9А йорт, 3 каб. адресы буенча урнашкан "Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе" муниципаль бюджет учреждениесенә территорияне ызанлау проекты буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар тапшырырга.

2.5. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар 2020 елның 27 мартына кадәр кабул ителә.

3. Яңа Никольский авыл җирлеге башкарма комитетына (Дәүләтгәрәев Х.Х.) гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә тәкъдим итәргә.

4. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Муниципаль район
башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.А. Зимин